| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2025 елның 27 октябре** Бишня ав. **№ 105**

Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 17.03.2022 елның 5 номерлы карары белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү турында (Бишнә авыл җирлеге башкарма комитетының 04.07.2022 елның 14 номерлы, 21.10.2022 елның 26 номерлы, 25.08.2023 елның 32 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 31.07.2025 елгы 304-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5.1 пунктның 4 пунктчасында «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.5.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«4.1) мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү вәкаләтләрен үтәү өчен ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы ярдәмендә бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый белешмәләр күрсәтелмичә, мондый затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән максатларда мондый затның шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын алу таләп ителми.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль

районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru («Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы:** **И.М.Фатхуллин**